КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 29 май г.Казань № 752

Психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ балалар өчен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең исемен үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ балалар өчен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе исемен «Росток» республика психолог-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба - Үзәк) үзгәртү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Үзәк эшчәнлегенең төп максаты - психолог-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм күрсәтү;

Үзәк белем алучыларга коррекция-үстерү, компенсация һәм логопед ярдәмен гамәлгә ашыра, укучыларга, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) һәм хезмәткәрләренә психологик-педагогик консультацияләр бирә, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тәртибен профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны оештыра.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә Психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ балалар өчен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвен тәэмин итәргә.

4. Үзәкнең дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм

дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, бу карарның 3 пунктын үтәгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасының кайбер норматив хокукый актларын бу карарның 1 пунктына туры китерү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ балалар өчен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең исемен үзгәртү турында» 2015 ел, 5 июнь, 420 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ балалар өчен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең исемен үзгәртү турында» 2015 ел, 5 июнь, 420 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 18 гыйнвар, 15 нче.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин